Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Питрәч авыл җирлеге Советы

Питрәч авыл җирлеге башлыгы
КАРАРЫ

4 апрель, 2025 ел № 2

«2024 елгы Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге Советы карары проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү хакында

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге уставының 23 статьясы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлегендә яшәүчеләрнең хокукларын үтәү максатларында «2024 елгы Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге бюджетын үтәү турында» Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлегенең карары проекты буенча фикер алышуда катнашу өчен Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге территориясендә җәмәгать фикер алышуын һәм гавами тыңлауларны оештыру тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге Советының 2017 елның 18 августындагы 65 номерлы (2017 елның 15 декабрендәге 79 номерлы, 2018 елның 25 маендагы 92 номерлы, 2019 елның 8 октябрендәге 137 номерлы, 2022 елның 16 декабрендәге 60 номерлы, 2023 елның 31 мартындагы 69 номерлы карарлар редакциясендә) карары белән карар бирәм:

1. «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге бюджетының 2024 елгы үтәлеше турында» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге Советының (алга таба - Совет карары проекты) карары проекты буенча гавами тыңлаулар уздырырга.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

2.1. гавами тыңлаулар уздыруны оештыручы - Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге башкарма комитеты;

2.2. гавами тыңлаулар уздыру датасы һәм вакыты - 2025 елның 30 апреле, 14.00 сәгать;

2.3. гавами тыңлаулар үткәрү урыны - Питрәч авылы, Совет урамы, 18 йорт, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының кече залы;

2.4. Питрәч авылы, Совет урамы, 18 нче йорт адресы буенча фамилиясен, исемен, атасының исемен, туган елын, яшәү урыны адресын күрсәтеп, Совет карары проекты буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр тапшырылырга мөмкин.

3. Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге башкарма комитетына:

3.1. Советның карар проектын Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) 2025 елның 18 апреленнән дә соңга калмыйча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә);

3.2. Советның билгеләнгән тәртип һәм әлеге карар белән билгеләнгән срокларда карары проекты буенча гавами тыңлаулар әзерләргә һәм уздырырга;

3.3. гавами тыңлаулар уздыру йомгаклары буенча Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге Советына гавами тыңлаулар беркетмәсен, гавами тыңлаулар бәяләмәсен, шулай ук Советның эшләнеп беткән (үзгәрешләр кертелгән очракта) проектын тәкъдим итәргә;

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Питрәч муниципаль районы
Питрәч авыл җирлеге башлыгы Р.Ә. Сөләйманов